**«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм
аларның статусы турында**

**Татарстан Республикасы
ЗАКОНЫ**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2005 елның 26 гыйнварында
кабул ителде

*(2008 елның 23 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы, 2010 елның 22 маендагы 27-ТРЗ номерлы, 2013 елның 13 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы, 2014 елның 22 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы ТР законнары редакциясендә)*

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә "Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеген төзи, «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составына керүче җирлекләрнең чикләрен билгели, аларга тиешле статус бирә.

**1 статья.** «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеген төзергә һәм аңа муниципаль район статусын бирергә.

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендә билгеләргә.

Тәтеш шәһәрен «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең административ үзәге дип билгеләргә.

**2 статья.** "Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче һәм Тәтеш шәһәреннән һәм, Красная Поляна, Любимовка авыллары территорияләрен дә кертеп, аның янәшәсендәге территорияләрдән гыйбарәт "**Тәтеш** шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 3 нче кушымта) нигезендә билгеләргә, аңа шәһәр җирлеге статусын бирергә. *(статья 2008 елның 23 декабрендәге 132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

**3 статья.** «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керә торган түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 4 – 35 нче кушымталар) нигезендә билгеләргә, аларга авыл җирлеге статусын бирергә һәм административ үзәкләрен расларга:

Алабирде авыл ќирлеге: Алабирде авылы (административ үзәк);

Байраш авыл ќирлеге: Байраш авылы (административ үзәк);

Бакырчы авыл ќирлеге: Бакырчы (административ үзәк), Үтәмеш, Татар Чагылдымы, Чуаш Чагылдымы, Чуаш Чурапаны авыллары, Татар Чурапаны поселогы;

Бидәңге авыл ќирлеге: Татар Бидәћгесе авылы (административ үзәк);

Бессоново авыл ќирлеге: Бессоново (административ үзәк), Югары Тархан авыллары;

Зур Әтрәч авыл ќирлеге: Зур Әтрәч (административ үзәк), Кече Әтрәч, Никифоровка авыллары;

Олы Тархан авыл ќирлеге: Олы Тархан (административ үзәк), Түбән Тархан авыллары, Мәмәй, Тљкђш поселоклары;

Олы Тормы авыл ќирлеге: Олы Тормы (административ үзәк), Кече Тормы, Чолы авыллары;

Олы Шәмәк авыл ќирлеге: Олы Шәмәк (административ үзәк), Кече Бисәр, Кече Шәмәк, Кече Фролово авыллары, Победа поселогы;

Жуково авыл ќирлеге: Жуково авылы (административ үзәк), Иоково, Кызыл Тархан, Берлек, Яңа Сумароков авыллары;

Килдеш авыл ќирлеге: Килдеш (административ үзәк), Кызыл Књл авыллары;

Киртәле авыл ќирлеге: Киртәле (административ үзәк), Кадыш, Васильевка, Красный Восток авыллары;

Келәш авыл ќирлеге: Келәш (административ үзәк), Тоншерма авыллары;

Кошки-Новотимбаево авыл ќирлеге: Кошки-Новотимбаево (административ үзәк), Яћа Льяшево Пњчинкђсе, Ивановка, Максимовка, Салмановка, Иске Колмәт, Чуаш Тайбасы авыллары;

Льяшево авыл ќирлеге: Льяшево (административ үзәк), Олы Бисәр, Ямбакты авыллары;

Монастырский авыл ќирлеге: Монастырский (административ үзәк), Лаптевка, Баймђт, Долгая Поляна, Ильинский авыллары;

Нармонка авыл ќирлеге: Нармонка (административ үзәк), Зеленовка, Колунец, Чинчурино, Кушкуй авыллары;

Сөендек авыл ќирлеге: Сөендек (административ үзәк), Башчы авыллары;

Урюм авыл ќирлеге: Пролей-Каша (административ үзәк), Богдашкино, Кашка, Урюм, Ивановка авыллары, Пищемар поселогы;

Федоровка авыл ќирлеге: Федоровка (административ үзәк), Алекина Поляна, Удельное Нечасово, Кызыл Йолдыз, Красное Нечасово авыллары. *(статья 2013 елның 13 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

**4 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан, Кремль
2005 елның 31 гыйнвары
№ 41-ТРЗ

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# “Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге составына керә торган муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- 35 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 50(3) - 67(4) | - Ульяновск өлкәсе |
| 67(4)-19(36) | - Буа муниципаль районы |
| 2(35)-19(36) | - Апас муниципаль районы |
| 28(34)-2(35) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 50(3)-28(34) | - Спас муниципаль районы |

«Тәтеш муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керә торган
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлекләр |
|---|---|
| 1 | Тәтеш шәһәре |
| 2 | Алабирде авыл җирлеге |
| 3 | Байраш авыл җирлеге |
| 4 | Бакырчы авыл җирлеге |
| 5 | Бидәңге авыл җирлеге |
| 6 | Бессоново авыл җирлеге |
| 7 | Зур Әтрәч авыл җирлеге |
| 8 | Олы Тархан авыл җирлеге |
| 9 | Олы Тормы авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шәмәк авыл җирлеге |
| 11 | Жуково авыл җирлеге |
| 12 | Килдеш авыл җирлеге |
| 13 | Киртәле авыл җирлеге |
| 14 | Келәш авыл җирлеге |
| 15 | Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге |
| 16 | Льяшево авыл җирлеге |
| 17 | Монастырский авыл җирлеге |
| 18 | Нармонка авыл җирлеге |
| 19 | Сөендек авыл җирлеге |
| 20 | Урюм авыл җирлеге |
| 21 | Федоровка авыл җирлеге |

;

*(1 нче кушымта 2013 елның 13 апрелендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

*(2 нче кушымта 2014 елның 22 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә)*

**“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама “Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Тәтеш муниципаль районы Буа, Апас, Кама Тамагы, Спас муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә Тәтеш, Спас муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 8,5 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 50 нче (3 нче) тоташу ноктасынннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Тәтеш, Буа муниципаль районнары һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Сөендек авылыннан 4,0 км төньяк-көнбатышта Чынлы елгасы акваториясендә урнашкан 67 нче (4 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чиге “Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә Тәтеш, Кама Тамагы һәм Апас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кече Әтрәч авылыннан 3,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче (35 нче) тоташу ноктасыннан алып 500 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,9 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Кариле участок урманчылыгындагы 40, 42, 45 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 45 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,3 км һәм 46 нчы урман кварталы буйлап 600 м бара, аннары 46 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, төньякка таба 1,0 км һәм төньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м, шуннан соң, 45 нче, 42 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнчыгышка таба, 44 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 800 м көньяк-көнчыгышка таба, 550 м көнчыгышка таба, 700 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 49 нчы, 50 нче урман кварталларының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 2,2 км уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 50 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап, көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең

төньяк чиге буйлап 100 м бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, 48 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 150 м, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 50 м урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр, шушы инеш агымы буенча 450 м аска таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 30 м урман массивы буйлап, сынык сызык ясап, 450 м төньяк-көнбатышка таба “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 128 нче урман кварталының төньяк чиге һәм 127 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, сынык сызык ясап, 3,8 км көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 127, 126, 125, 124 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньяк-көнбатышка таба 124 нче, 129 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш, төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 5,0 км көньяк-көнчыгышка таба, инешләрне кисеп үтеп, 129, 131, 133 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,1 км төньяк-көнбатышка таба 133 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м төньяк-көнчыгышка таба 133 нче, 134 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,3 км төньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 134 нче, 132 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 125 нче, 126 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 900 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара, 149 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, инешне кисеп үтә, 50 м көньякка таба урман массивының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м бара, аннары 149 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 135 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш, көнбатыш, көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 1,6 км һәм 136 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 1,9 км бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м төньяк-көнчыгышка таба, Тәтеш – Кама Тамагы автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба, урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 20 м уза, аннары, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба 67 нче урман кварталының төньяк, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап 2,2 км, Куйбышев сусаклагычының текә уң яры буйлап 50 м бара, шуннан соң 650 м әлеге сусаклагыч акваториясе буйлап Тәтеш, Кама Тамагы һәм Спас муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Долгая Поляна авылыннан 2,6 км көньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 28 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чиге “Апас муниципаль районы” муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 2 нче (35 нче) тоташу

ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне кисеп үтеп, 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, 2,4 км көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м, урман утыртмалары буйлап, сынык сызык ясап, 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 950 м бара, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м һәм көньяк-көнбатышка таба 350 м уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, чокырларны кисеп үтеп, 750 м бара, аннары көньяк-көнбатышка таба агач-куак полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, агач-куак массивы буйлап 50 м, агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, агач-куак массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, шуннан соң агач-куак массивы буйлап 50 м Гремячий инешенә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча 3,5 км аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 850 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, Гремячий инешенең текә ярын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, карьер буенча 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м Үләмә елгасына кадәр уза, аннары шушы елгы агымы буенча 3,0 км өскә таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 800 м, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 5,1 км бара, аннары 1,1 км көньяк-көнчыгышка таба, 2,3 км көньяк-көнбатышка таба, инешне кисеп үтеп, Тормы инешенә кадәр уза, шуннан соң бу инеш агымы буенча 200 м өскә таба кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, аннары бу кибеп баручы инеш коя торган инеш агымы буенча 2,2 км өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба бара, аннары агач-куак массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м бара, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, “Буа урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 39 нчы, 37 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл кырыендагы урман полосаларын кисеп үтеп, 600 м көнбатышка таба бара, аннары 900 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр уза, инеш агымы буенча 500 м аска таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 20 м көньякка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 400 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 100 м, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 650 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тәтеш, Апас һәм Буа муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кече Фролово авылыннан 4,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 19 нчы (36 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге чиге “Буа муниципаль районы” муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 67 нче (4 нче) тоташу ноктасыннан алып Чынлы елгасы агымы буенча 1,2 км аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе агач-куак массивын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,5 км төньяк-

көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба, 200 м көньяк-көнчыгышка таба Зөя елгасына кадәр, бу елганың агымы буенча 24,1 км аска таба, “Казан – Ульяновск” – Олы Тархан автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Килнә елгасы тамагына кадәр бара, шуннан соң бу елга агымы буенча 2,0 км өскә таба инеш тамагына кадәр уза, аннары бу инеш агымы буенча 300 м өскә таба, буа буйлап 150 м, инеш агымы буенча 2,9 км өскә таба бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, кибеп баручы инешкә кадәр уза, аннары бу инеш агымы буенча 650 м өскә таба, сынык сызык ясап, 2,9 км көньяк-көнчыгышка таба, буаны кисеп үтеп, “Буа урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 81, 82, 83, 87 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 7,4 км төньяк-көнбатышка таба 87, 88, 85, 86, 80 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешне һәм буаларны кисеп үтеп, инешкә кадәр бара, аннары инеш агымы буенча 2,0 км аска таба буага кадәр бара, шуннан соң буаның уң яры буенча 20 м һәм төньякка таба, буаны кисеп үтеп, 20 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 127 нче урман кварталының аерымланган кишәрлеге буйлап 200 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 127 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км һәм төньяк-көнчыгышка таба 950 м бара, шуннан соң “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 57, 56, 55, 54, 52, 51 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 7,7 км төньякка таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, 48 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 950 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнчыгышка таба урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м көньяк-көнбатышка таба һәм 450 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң 40, 39, 38, 32 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 6,9 км көнбатышка таба уза, 32 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнбатышка таба, 32 нче урман кварталының көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре һәм 28 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, сынык сызык ясап, төньяк-көнбатышка таба 22 нче, 21 нче урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 2,8 км, урман полосасының көньяк чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасының көньяк чиге буйлап 450 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, инешләрне, Шигали һәм Тоншерма авылларын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,7 км көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 1,1 км уза, аннары көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м бара,

шуннан соң “Буа урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 550 м төньяк-көнбатышка таба һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м көньяк-көнбатышка таба, урман утыртмалары буенча 50 м, чокырларны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,2 км, 126 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары 64, 62, 59 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 3,5 км, 59 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 450 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Кыят – Күгәлнә – Тоншерма автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м бара, аннары төньяк-көнбатышка таба урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм төньякка таба 250 м бара, шуннан соң урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 20 м, сынык сызык ясап, 50 нче урман кварталының көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, Зөя елгасына кадәр 4,2 км бара, шушы елга агымы буенча 2,8 км аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр аның сул ярындагы текә ярларны кисеп үтеп бара, шуннан соң бу инеш агымы буенча 600 м өскә таба, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба чокыр төбеннән 400 м, чокырның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм, сынык сызык ясап, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км бара, чокырның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап 350 м уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Буа – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м, чокыр төбеннән 400 м Тоша елгасына кадәр бара, шуннан соң елга агымы буенча 200 м аска таба аңа коя торган инеш тамагына кадәр бара, аннары әлеге инеш агымы буенча 1,4 км өскә таба бу инешкә коя торган кибеп баручы инеш тамагына кадәр уза, шуннан соң кибеп баручы инеш агымы буенча 350 м өскә таба, төньяк-көнчыгышка таба урман массивы буйлап 100 м бара, аннары 36 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап, сынык сызык ясап, 800 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м һәм төньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м бара, шуннан соң төньякка таба урман полосасы буйлап 100 м, урман полосасының көнбатыш чиге буйлап 50 м, урман полосасы буйлап 150 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 350 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м, “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 152 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м һәм шушы участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, сынык сызык ясап, 2,1 км бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, урман полосасы буйлап, сынык сызык ясап, 1,2 км уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап 30 м, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м, урман полосасы буйлап 1,0 км, урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м, уйсулыктагы сазлыкның көнчыгыш чиге буйлап 40 м, урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 600 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң урман массивының көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м һәм төньяк-көнбатышка таба 700 м, урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м уза, аннары урман полосасы буйлап 750 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 30 м бара, шуннан соң, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 500 м, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м уза, аннары урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 300 м, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлын, "Апас – Тәтеш" – Олы Шәмәк – Кече Шәмәк автомобиль юлын тоташтыра торган профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм текә участокны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м бара, шуннан соң 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 20 м төньякка таба һәм төньяк чиге буйлап 50 м көнбатышка таба уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 113 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 100 м бара, аннары урман массивының көнбатыш чиге буйлап 50 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м, урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Ульяновск федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм юл кырыендагы урман полосаларын кисеп үтеп, 550 м, урман массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары, сынык сызык ясап, 1,7 км төньякка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Төбәк Черкене участок урманчылыгындагы 58 нче, 57 нче урман кварталларының көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап, 550 м көньяк-көнбатышка таба, кибеп баручы инешләрне кисеп үтеп, 57 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 400 м төньяк-көнбатышка таба 65 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап 19 нчы (36 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге чиге "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 50 нче (3 нче) тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 28 нче (34 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында" Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

*(3 нче кушымта 2014 елның 22 ноябрендәге*
*99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы*
*Законы редакциясендә)*

**Тәтеш муниципаль районының**
**“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясе**
**чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге Льяшево, Монастырский, Нармонка, Урюм авыл җирлекләре һәм Спас муниципаль районы белән чиктәш.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге Нармонка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге, Нармонка һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Льяшево авылыннан 2,7 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасы буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м, 2,3 км урман полосасы буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 50 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 1,9 км аска таба ул Үләмә елгасына койган җиргә кадәр бара, шушы елга агымы буенча 200 м өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, шуннан соң бу инеш агымы буенча 1,6 км өскә таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буе урман массивын, кибеп баручы инешне һәм текә ярны кисеп үтеп, 850 м көньяк-көнчыгышка таба, Буа – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм урман полосасын кисеп үтеп, 2,6 км көньяк-көнбатышка таба, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба кибеп баручы инешнең чишмә башына кадәр бара, бу инеш агымы буенча 650 м аска таба ул Бизә елгасына койган җиргә кадәр уза, аннары бу елга агымы буенча 100 м өскә таба аңа коя торган инеш тамагына кадәр бара, шуннан соң бу инеш агымы буенча 3,9 км өскә таба аның чишмә башына кадәр уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м, “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 400 м, урман массивы буйлап 350 м, урман массивын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км, 164 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге, Нармонка һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кашка авылыннан 3,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге, Льяшево, Зур Әтрәч һәм

Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасыннан алып 10 м көньякка таба “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көньякка таба, 750 м көньяк-көнбатышка таба инешкә кадәр уза, бу инеш агымы буенча 500 м аска таба буага кадәр бара, аннары буа буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң инеш агымы буенча 1,7 км аска таба бара, аннары көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 2,8 км урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 23 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге Монастырский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге, Монастырский авыл җирлеге һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Ильинский авылыннан 3,5 км көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 27 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 850 м, “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 74 нче урман кварталы буйлап 450 м уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 350 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 150 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м көньяк-көнбатышка таба, текә ярны берничә тапкыр кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 500 м, 74 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 750 м бара, көнбатышка таба 139 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 20 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Тәтеш – Кама Тамагы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м, урман массивының көньяк чиге буйлап 300 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, текә ярларны, урман полосасын, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,4 км Үләмә елгасына кадәр бара, аннары бу елга агымы буенча 650 м аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,0 км көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 4,7 км төньякка таба бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 600 м төньяк-көнбатышка таба, 350 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге Спас муниципаль районы белән чиктәш җирдә 27 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап “Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге, Урюм авыл җирлеге һәм Спас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Тәтеш шәһәреннән 850 м көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 25 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш шәһәре” муниципаль берәмлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 25 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба, сусаклагычның текә уң ярын кисеп үтеп, Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 850 м, “Тәтеш урманчылыгы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 78 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м уза, аннары көньякка таба 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м, 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 100 м уза, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м, 78 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 400 м бара, шуннан соң 250 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 79 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 500 м көньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 1,6 км көньякка таба бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 83 нче, 82 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап 550 м уза, күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м, 82 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 м бара, Тәтеш – Олы Тархан – Ундоры автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 700 м уза, аны кисеп үтә һәм 81 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап 50 м бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, аннары 1,6 км төньяк-көнбатышка таба 81 нче, 80 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 650 м көньяк-көнбатышка таба 80 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, сынык сызык ясап, 1,8 км көньяк-көнчыгышка таба 80 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 169 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, урман массивын кисеп үтеп, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 26 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында” Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта
*(4 нче кушымта 2014 елның 22 ноябрендәге
99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы
Законы редакциясендә)*

## Тәтеш муниципаль районының “Алабирде авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама “Алабирде авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең

территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Алабирде авыл җирлеге Байраш, Зур Әтрәч, Олы Тормы һәм Льяшево авыл җирлекләре белән чиктәш.

Алабирде авыл җирлеге чиге Олы Тормы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Алабирде, Олы Тормы һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Алабирде авылыннан 1,8 км көньяк-көнбатышта урнашкан 9 нчы тоташу ноктасыннан алып 2,8 км төньяк-көнбатышка таба, инешне һәм “Апас – Тәтеш” – Алабирде – Кече Әтрәч автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Алабирде, Олы Тормы һәм Байраш авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Байраш авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Алабирде авыл җирлеге чиге Байраш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Алабирде, Байраш һәм Зур Әтрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Никифоровка авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып Үләмә елгасы агымы буенча 2,4 км өскә таба уза, аннары 1,2 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Алабирде авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, яр буендагы агач-куак полосасын һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 750 м көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба, 2,5 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары урман утыртмаларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, чокырны кисеп үтеп, 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м һәм көньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне, текә ярны һәм “Апас – Тәтеш” – Алабирде – Кече Әтрәч автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 3,2 км, урман утыртмаларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 3,2 км, Шонга елгасын, аның текә сул ярын һәм текә ярны кисеп үтеп, Алабирде, Зур Әтрәч һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Әтрәч авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Алабирде авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 10 нчы тоташу ноктасыннан алып 2,0 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр уза, шуннан соң бу инеш агымы буенча 1,9 км аска таба ул Шонга елгасына койган җиргә кадәр бара, бу елга агымы буенча 550 м аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньяк-көнбатышка, чокырларны һәм Алабирде – Ямбакты автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 2,0 км көньяк-көнбатышка таба, Үләмә елгасын кисеп үтеп, 950 м төньяк-көнбатышка таба, 450 м көньяк-көнбатышка таба бара, урман полосасының төньяк чиге буйлап 1,2 км 9 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль<br>берәмлегенең һәм аның составындагы<br>муниципаль берәмлекләрнең территорияләре

чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында” Татарстан Республикасы Законына
5 нче кушымта
*(5 нче кушымта 2008 елның 23 декабрендәге
132-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы
Законы белән кертелде,
Үз көчен югалтты. – 2010 елның 22 маендагы
27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы*

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында” Татарстан Республикасы Законына
6 нчы кушымта
*(6 нчы кушымта 2014 елның 22 ноябрендәге
99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы
Законы редакциясендә)*

**Тәтеш муниципаль районының
“Байраш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе
чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама “Байраш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын (“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Байраш авыл җирлеге Алабирде, Зур Әтрәч, Олы Тормы авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы белән чиктәш.

Байраш авыл җирлеге чиге Апас муниципаль районы белән чиктәш җирдә Байраш, Олы Тормы авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кече Шәмәк авылыннан 3,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 6 нчы тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Байраш, Зур Әтрәч авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Никифоровка авылыннан 1,4 км көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Байраш авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Байраш, Зур Әтрәч һәм Алабирде авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Никифоровка авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып Үләмә елгасы агымы буенча 2,4 км аска таба 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Байраш авыл җирлеге чиге Алабирде авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып Үләмә елгасы агымы буенча 2,4 км өскә таба уза, аннары

1,2 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Байраш, Алабирде һәм Олы Тормы авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Байраш авылыннан 1,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 8 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Байраш авыл җирлеге чиге Олы Тормы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 8 нче тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Апас – Тәтеш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм ясалма сулыкны кисеп үтеп, 4,4 км көньяк-көнбатышка таба, чокырларны һәм кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 2,1 км төньяк-көнбатышка таба 6 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

“Тәтеш муниципаль районы” муниципаль
берәмлегенең һәм аның составындагы
муниципаль берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү һәм аларның статусы
турында” Татарстан Республикасы Законына
7 нче кушымта
*(7 нче кушымта 2014 елның 22 ноябрендәге*
*99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы*
*Законы редакциясендә)*

**Тәтеш муниципаль районының**
